ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 38 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш); 2022, № 57 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $10^3$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«$10^3$. Төзү һәм файдалануга тапшыру аерым этаплап башкарылган күпфатирлы йортлар капиталь ремонт буенча региональ программага, аны актуальләштергәндә, күпфатирлы йорт төзелешенең соңгы этабын файдалануга тапшырганнан соң кертелә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 26 декабрь
№ 100-ТРЗ